МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.03.2021 г.Казань № 150

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 12 апрелендә 7637 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 19 мартындагы 150 номерлы боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 06 апрелендәге 254 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 25.07.2018 №703, 18.09.2018 №885, 24.06.2019 №494, 17.10.2019 №853, 09.04.2020 №238, 14.07.2020 №516, 09.10.2020 №717 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2 бүлекнең 2.5 пунктында «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән баланың (балаларның) тууын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе;»;

3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән ананың (әтисенең) үлеме турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе;»;

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

икенче абзацта «- Татарстан Республикасы территориясендә бала (балалар) тууны дәүләт теркәвенә алу очракларында» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «- Татарстан Республикасы территориясендә үлем актын теркәү очракларында» сүзләрен төшереп калдырырга;

алтынчы абзацта «җирле үзидарә органнарында» сүзләрен «вәкаләтле органнарда» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «(вәкаләтле органнарда)» сүзләрен өстәргә;

2.8 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып, булган мәгълүматлар һәм (яки) документлар нигезендә, аны алу хокукының булмавы тора»;

3 бүлектә:

3.4.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Үзәк бүлеге хезмәткәре электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында, – вәкаләтле органнардан;

анасының (атасының) үлемен дәүләт теркәвенә алу турында – вәкаләтле органнардан;

әлеге Регламентның 2.5 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш, Татарстан Республикасы территориясендәге авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими, кимендә өч ел яшәү фактын раслый торган, – вәкаләтле органнардан;

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: алынган мәгълүматлар.»;

3.4.2 пунктчада:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бала (балалар) тууын дәүләт теркәвенә алу турында – вәкаләтле органга»;

дүртенче абзацта «Татарстан Республикасы территориясендә үлем актын теркәү очракларында,» сүзләрен төшереп калдырырга;

алтынчы абзацта «җирле үзидарә органнарыннан» сүзләрен «вәкаләтле органнардан» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булмавы турында – вәкаләтле органга»;

5 бүлекнең 5.1 пунктының дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, Чечен Республикасында һәм Төньяк Кавказның аның янәшәсендә үк урнашып, кораллы низаг зонасына кертелгән территорияләрендә халыкара булмаган кораллы низаг шартларында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, шулай ук Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр барышында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә һәлак булган (үлгән), хәбәрсез югалган, инвалид булып калган хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләре һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләре балаларының җәйге сәламәтләндерү ялын уздыруга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 20 июнендәге 445 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 04.09.2014 №485, 07.06.2016 №317, 11.07.2016 №399, 08.06.2017 №351, 07.05.2018 №352, 18.09.2018 №885, 07.05.2019 №324, 14.11.2019 №1011, 25.03.2020 №193, 14.07.2020 №517, 16.10.2020 №735 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, Чечен Республикасында һәм Төньяк Кавказның аның янәшәсендә үк урнашып, кораллы низаг зонасына кертелгән территорияләрендә халыкара булмаган кораллы низаг шартларында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, шулай ук Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр барышында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә һәлак булган (үлгән), хәбәрсез югалган, инвалид булып калган хәрби

хезмәткәрләрнең аерым категорияләре һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләре балаларының җәйге сәламәтләндерү ялын уздыруга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2 бүлекнең 2.14 пунктында:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

в) чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән баланың (балаларның) тууын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыкның күчермәсе һәм аның нотариаль рәвештә рус теленә күчерелүе турында таныклыкның күчермәсе, гражданлык хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелә;»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «4.1» саннарын «4.2» саннарына алмаштырырга;

2.6 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда)»;

3 бүлектә:

3.4.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бала (балалар) тууын дәүләт теркәвенә алу турында, – вәкаләтле органнардан»;

3.4.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бала (балалар) тууын дәүләт теркәвенә алу турында – вәкаләтле органга».